РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
КУЮК-ЕРЫКСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Вахитова, д.1а, с. Новый Кумазан,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422151

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӨЕК-ЕРЫКСА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ
Вахитов ур., 1а нче йорт, Яңа Комазан авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422151

тел.(факс): (85563) 3-67-33; e-mail: Kuer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар
19.02.2021 ел

Постановление
№ 6

Карарга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек- Ерыкса авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 15 июлендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек- Ерыкса авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 22 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Дәүләт муниципаль хезмәтләре күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгының, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 2021 елның 4 январендәге №ПР -3 уртак коллегия беркетмәсе нигезендә Көек- Ерыкса авыл җирлеге Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Көек- Ерыкса авыл җирлеге Башкарма комитеты күрсәтә торган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек- Ерыкса авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 15 июлендәге (2020 елның 24 гыйнварындагы 3 карарлары редакциясендә, 11.01.2021, № 1) 22 номерлы карарының 1.3,1.6 пунктларына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. «Агач һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын кыскартуга һәм утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында (3 нче кушымта);

1.1.1 2.5 пунктка түбәндәге эчтәлекле 9 пунктча өстәргә:

«9) Салым органының Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмәсе.».

1.1.2 2.6 пунктын түбәндәге эчтәлекле 2 пунктча өстәргә:

«2) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм

башка түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмәләр.».
1.1.3 2.8 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:
«5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булу.».
1.1.4 3.4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Башкарма комитет белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем керә ала торган мәгълүматлар), салымнар, җыемнар, пенялар һәм законнарны бозган өчен штрафлар түләү буенча бурычлар булу (булмау) турында белешмәләрне электрон рәвештә җибәрә. Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән көннән алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.
Процедураның нәтиҗәсе: җибәрелгән сорату.»

1.1.5 1нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле 8 пункт өстәргә:
«8) Салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычларның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына булмавы турында салым органыннан белешмә.».

1.2 Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында (6 нчы кушымта);
1.2.1 1.5. пунктындагы икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«җирле үзидарә органнары бирә торган белешмәләр (өземтә) дигәндә хуҗалык кенәгәсеннән өземтә, йорт китабыннан архив өземтә, алдагы яшәү урыныннан белешмә, көнкүреш характеристикасы дип аңлашыла.»;
1.2.2 2.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Муниципаль хезмәт күрсәтүләрне алу өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге документларны тапшыра:
1) шәхесне таныклый торган документ;
2) мөрәҗәгать итүче вәкиле вәкиле вәкаләтләрен таныклаучы документ, муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта (физик затларның законлы вәкилләреннән тыш);
3) гариза:
- кәгазь чыганактагы документ рәвешендә (1 нче кушымта);
- республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, электрон рәвештә (интерактив формага тиешле белешмәләр кертү юлы белән тутырыла);
«Электрон имза турында» 2011 елның 06 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган электрон рәвештә (интерактив формага тиешле

белешмәләр кертү юлы белән тутырыла);

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси мәгълүматларын эшкәртү кирәк булган очракта һәм әгәр федераль закон нигезендә мондый шәхси белешмәләрне эшкәртү күрсәтелгән затның ризалыгы белән башкарылырга мөмкин булса, муниципаль хезмәт алуны сорап мөрәҗәгать итүче өстәмә рәвештә күрсәтелгән затның яисә аның күрсәтелгән затның шәхси күрсәткечләрен эшкәртүгә законлы вәкиленең ризалыгын алуны раслый торган документлар тапшыра. Килешү алуны раслый торган документлар шул исәптән электрон документ рәвешендә дә тапшырылырга мөмкин

Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану өчен гариза бланкын, шәхси мөрәҗәгать итеп, башкарма комитетта алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аның белән бергә тапшырыла торган документлар гариза бирүче тарафыннан, түбәндәге ысулларның берсен сайлап, кәгазьдә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

- шәхсән (мөрәҗәгать итүче исеменнән ышанычнамә нигезендә эш итүче зат тарафыннан);
- почта аша.

Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан Республика порталы аша электрон документлар рәвешендә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.»;

1.2.3 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә:

1.2.4 2нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

1.3. Әлеге карарны аны Мамадыш муниципаль районының рәсми mamamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә (pravo.tatarstan.ru).

1.4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгым калдырам.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Көек- Ерыкса авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе

Ф.Р. Шәйхетдинов

1 нче кушымта

В ___________________________________________
(җирле үзидарә органы исеме
___________________________________________
муниципаль берәмлек башлыгы)
___________________________________________
__________________ (алга таба-гариза бирүче).
(фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспорт мәгълүматлары, яшәү урыны буенча теркәлү, телефоны)

Гариза
белешмә (өземтә) бирү турында

Белешмә (өземтә) бирүегезне сорыйм_________________________.

Адресы буенча:______________

Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:
1. ___________________________________________
2. ___________________________________________
3. ___________________________________________

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында түбәндәге ысул белән хәбәр итүегезне сорыйм:

______________ ___________ ________________________________________
(дата) (имза) (ФИАИ)